**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

---

2024 елның 11 июне 46-РС номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуları барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау хакында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында» гы нигезләмәне, кушымта нигезендә, расларга.

2. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2016 елның 11 апрелендәге 20-РС номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан

Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башлыгы урынбасары - Лаеш муниципаль районы Советы рәисе урынбасары Т.П. Борһановага йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы
Советының 2024 елның 11 июнендәге 46-РС
номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе ачыклана.

2. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм муниципаль хезмәткәрләр коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу чараларын күрергә тиеш.

3. Хәбәр вазифаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү рәвешендә язма рәвештә рәсмиләштерелә (алга таба - хәбәрнамә).

4. Хәбәрнамә муниципаль вазыйфаны биләүче затка аның мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган көннән соң эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

5. Хәбәрнамәдә бәян ителгән шартларга мөнәсәбәте булган материаллар булганда, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, муниципаль хезмәткәрләр аларны хәбәрнамә белән бергә тапшыралар..

6. Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр хәбәрнамәгә кертелми. Кирәкле очракларда мондый белешмәләр яшеренлек режимын тәэмин итү һәм дәүләт серен саклау буенча Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп тапшырыла.

7. Муниципаль хезмәткәрләр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча хәбәрнамә җибәрә.

8. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар муниципаль районның башкарма комитеты җитәкчесе муниципаль районның вәкиллекле органы рәисенә

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендәге рәвеш буенча хәбәрнамә җибәрә.

9. Әлеге Нигезләмәнең 7 һәм 8 пунктлары нигезендә кергән мөрәҗәгатьләр җирле үзидарә органының кадрлар бүлекчәсенә яисә коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба - кадрлар хезмәте) тиешле теркәү журналында кичекмәстән теркәлү өчен тапшырыла (3 нче кушымта).

Теркәлгән хәбәрнамәнең күчермәсе, хәбәрнамә бирелгән көнне яисә аннан соңгы эш көнен күрсәтеп, хәбәр итүче затка тапшырыла йә аңа почта элемтәсе аша җибәрелә.

10. Белдерүне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләгәндә кадрлар хезмәтенең вазыйфаи затлары хәбәрнамә биргән зат белән әңгәмә уздырырга, аннан язма аңлатмалар алырга хокуклы, ә яллаучы (эш бирүче) вәкиле, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисе билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга запрослар җибәрә ала.

Хәбәрнамә, шулай ук йомгак һәм башка материаллар белдерү кергән көннән алып җиде эш көне эчендә хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе рәисенә (алга таба - Комиссия) тапшырыла. Сораулар юлланган очракта, хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә хәбәрнамә кергән көннән алып 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артык түгел.

11. Комиссия «Хезмәттәге (вазыйфаи) үз-үзен тотышына һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 26-РС номерлы карары белән расланган Комиссия турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә хәбәрнамәләрне карый һәм алар буенча карарлар кабул итә, һәм кабул ителгән карарны яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә), муниципаль районның вәкиллекле органы рәисенә юллый.

12. Эшкә алучының (эш бирүче) вәкиле, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисе хәбәрнамәне Комиссия карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликты булмавын танырга;

б) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан шәхси кызыксынучанлык мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерергә мөмкин дип танырга;

в) хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан яклар конфликтын җайга салу турында таләпләр үтәлмәгәнлеген танырга.

13. Әлеге Нигезләмәнең 12 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә яллаучының (эш бирүче) вәкиле, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисе мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу яисә аның барлыкка килүен булдырмау буенча чаралар күрә йә хәбәрнамә җибәргән затка мондый чаралар күрергә киңәш итә.

14. Әлеге Нигезләмәнең 12 пунктындагы «в» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, яллаучы (эш бирүче) вәкиле, муниципаль районның

вәкиллекле органы рәисе хәбәрнамә җибәргән затка карата Россия Федерациясе законнарында каралган юридик җаваплылык чарасын кулланалар.

15. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында каралган муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бурычларны үтәмәү Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту өчен нигез булып тора.

**Башлык урынбасары – муниципаль район**
**Советы рәисе урынбасары** **Т.П. Борһанова**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында
муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм җирл
е үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын
биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә
мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә
мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү
турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәгә 1 кушымта

______________________________
(танышу турында билге)

______________________________
(Ф.И.О., эшкә алучының (эш бирүченең) вәкиле вазыйфасы)

кемнән ______________________________

______________________________

_____________________________
(Ф.И.А., муниципаль хезмәткәр вазыйфасы,)

ХӘБӘРНАМӘ
Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга кирәк).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүнең нигезе булган хәлләр: _______________________________________________

___________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлыгы йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вазыйфаи бурычлар: ________________________________

___________________________________________________________________

Шәхси кызыксыну барлыкка килүнең нигезе булган хәлләр: _______________________________________________

___________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: _____________________________________________

___________________________________________________________________

Әлеге хәбәрнамәне караганда Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы мәнфәгатьләре конфликтын җайга салу һәм хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим).

___________________________________________________________________
(хәбәрнамә җибәрүче затның датасы, имзасы, инициаллары һәм фамилиясе)

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында
муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм җирл
е үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын
биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә
мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә
мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү
турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәгә 2 кушымта

_____________________________
(танышу турында билге)

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының вәкиллекле органы рәисенә

___________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

кемнән____________________________________________________

(муниципаль вазыйфаларны биләүче затның Ф.И.Аи., вәкаләтле зат вазыйфасы,

# ХӘБӘРНАМӘ

## Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга кирәк).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүнең нигезе булган хәлләр: ____________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлыгы йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вазыйфаи бурычлар: ______________________________________

Шәхси кызыксыну барлыкка килүнең нигезе булган хәлләр: ____________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ____________________________________________________

Әлеге хәбәрнамәне караганда Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы мәнфәгатьләре конфликтын җайга салу һәм хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим).

____________________________________________________

(хәбәрнамә җибәрүче затның датасы, имзасы, инициаллары һәм фамилиясе)

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм жирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакындагы нигезләмәгә 3 кушымта

# Журнал
## Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрләрне теркәү журналы

______________________________________________

(җирле үзидарә органы атамасы)

| хәбәрне теркәү номеры | Хәбәрнамәне теркәү датасы | Хәбәрнамә тапшырылды | | Хәбәрнамәнең кыскача эчтәлеге | Кабул ителгән чаралар | Хәбәрнамәнең күчермәсен алу турында яисә хәбәрнамәнең күчермәсен почта аша җибәрү турында тамга - почта буенча: |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфасы, бүлек исеме | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |